Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ

КАРАР

Менделеевск ш.

05.03.2026 ел

№ 33

Мөлкәтне федераль милеккә тапшыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Милекне федераль милектән Россия Федерациясе субъекты милкенә яисә муниципаль милеккә, Россия Федерациясе субъекты милкеннән федераль милеккә яисә муниципаль милеккә, муниципаль милектән федераль милеккә яисә Россия Федерациясе субъекты милкенә тапшыру турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеге хакында" 2006 елның 13 июнендәге 374 нче номерлы карары, "Конкуренцияне яклау турында" 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасы, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы хәрби часть командирының – 29656 нчы кыр часте үтенечен карап, махсус хәрби операция уздыру зонасында бурычларны үтәү өчен махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм чаралары күрсәтү максатларында,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. ТР Менделеевск муниципаль районының җирле үзидарә органы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына муниципаль милекне - 498945,40 сумлык, vin X9L212300G0579424, дәүләт номеры Х 703 КА 116 RUS Шевроле Нива автомобилен Россия Федерациясе Оборона министрлыгы федераль милкенә тапшыруны йөкләргә.

2. Менделеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына муниципаль мөлкәтне федераль милеккә тапшырганчы Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану турында килешү төзергә тәкъдим итәргә..

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. www.mendeleevsk.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының законлылыкны, хокук тәртибен һәм кеше хокукларын саклау буенча Даими комитетына йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары Л.К. Галеева